**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында» 2021 елның 6 маендагы ПУ-349 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 9 ноябрендәге 770 номерлы һәм 2025 елның 5 маендагы 332 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көнен Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына (алга таба – Оештыру комитеты) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Оештыру комитеты составыннан З.Р. Вәлиеваны, С.М. Захарованы, А.П. Комяковны, М.М. Миңнуллинны, Р.Н. Садыйковны, Р.Р. Фазыловны, А.Р. Хәйруллинны чыгарырга;

б) Оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

Абашев Альмир Рәшит улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Кадыйров Азат Рифгать улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Начвин Илья Сергеевичны – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

Сабирова Айгөл Азат кызын – «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Созинов Алексей Станиславовичны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисен (килешү буенча);

Терентьев Александр Михайловичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Хитрина Людмила Александровнаны – Казан шәһәренең «Бөек Ватан сугышы ветераннары – камалыштагы герой-шәһәр Ленинградта яшәүчеләр» җирле иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча);

в) Оештыру комитеты әгъзасы Р.Б. Зариповның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм идарәсе башлыгы».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 30 апрель
№ 355